Раслыйм:
«Сәләт» ТРЯИФ
генераль директоры
Җ.Ш. Сөләйманов

____________________

“5” апрель 2020-нче ел

«Arts Biler Forum» Форумын үткәрү турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

«Arts Biler Forum» Форум (алга таба – Форум) беренче тапкыр 2018-нче елда оештырыла. Быел традицион рәвештә Биләрдә дәүләт тарихи-археологик музей-тыюлыгы территориясендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән IX Халыкара «Сәләт» яшьләр белем бирү форумының икенче сменасы буларак үткәрелә.

Форум катнашучыларга иҗат лабораторияләре кысаларында уникаль белем һәм экспертлардан тәкъдимнәр алу, үзләрен белем бирү һәм мәдәни программасында күрсәтә алу, башка катнашучылар һәм экспертлар белән профессиональ мәдәни элемтәләр булдыру, төрле юнәлешләр һәм жанр үзенчәлекләре белән, шулай ук, сайлап алынган юнәлеш кысаларында яңа тенденцияләр белән танышу, киләчәк үсешкә этәргеч алу өчен мөмкинлекләр мохите булдыру максатыннан оештырыла.

Форум Татарстан Республикасы «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы белән берлектә оештырыла.

Форумны үткәрү өчен оештыручылар һәм чакырылган экспертлар арасыннан һәр этапны әзерләү һәм үткәрүне гамәлгә ашыручы Форумның башкарма дирекциясе (алга таба – Дирекция) төзелә.

2. Форумның максатлары һәм бурычлары

Форумның төп максаты итеп сәләтле балаларның, яшьләрнең, остазларның музыка, бию һәм театр сәнгате өлкәсендә иҗади потенциалын ачыклау, ачу, гамәлгә ашыру платформасын булдыру санала.

Форум бурычлары:

- Музыка, бию һәм театр сәнгате өлкәсендә сәләтле балаларны, яшьләрне ачыклау;

- иҗат белән кызыксынган яшьләрне берләштерүче, үстерүче, рухи һәм мәдәни баетучы мохит булдыру;
- милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне һәм татар телен саклап калу, үстерү һәм популярлаштыру;
- музыка, бию һәм театр сәнгате өлкәсендә катнашучыларның осталыгын арттыру;
- катнашучыларда иҗади эшчәнлеккә карата кызыксынуны ныгыту;
- катнашучыларның сайлап алынган юнәлештә кызыксынуларын арттыру;
- иҗади эшчәнлекнең төрле юнәлешләрен һәм жанрларын яшьләр арасында популярлаштыру;
- иҗади коллективлар һәм башкаручылар арасында һөнәри, мәдәни элемтәләр булдыру һәм ныгыту;
- проектта катнашучыларның һәм экспертларның үзара хезмәттәшлеге өчен мәйданчык булдыру;
- Татарстан Республикасы иҗади генофондын саклау һәм үстерү.

## 3. Форумны үткәрү этаплары

Форум 3 этапта үткәрелә:

1 этап – «Катнашучылардан гаризалар кабул итү»: **2020-нче елның 29-нчы апреленнән 24-нче маена** кадәр. Гаризалар **selet.biz** сайтында кабул ителә.

2 этап – «Читтән торып сайлап алу этабы»: **2020-нче елның 1-нче июненнән 6-нчы июненә** кадәр. Катнашучыларны сайлап алу эксперт комиссиясе тарафыннан Форумга тапшырылган гариза, күрсәтелгән казанышлар нигезендә үткәрелә.

3 этап – «Төп этап. Форумда катнашу»: **2020-нче елның 27-нче июненнән 2-нче июленә кадәр.** Форумның остаханәләр, тренинглар, иҗади очрашулар, түгәрәк өстәлләр, экспертлар комиссиясе тәкъдиме белән режиссер төркеме сайлап алган номерлардан торган гала-концерт чараларын үз эченә алган белем бирү, мәдәни программасында катнашу.

Эпидемиологик вәзгыятькә бәйле рәвештә Форумны үткәрү этаплары үзгәрә һәм Форумның үткәрелү вакыты кичектерелә ала. Моның турында катнашучыларга алдан хәбәр ителәчәк. Шулай ук яңалык белән **selet.biz** сайтында мөстәкыйль рәвештә танышып булачак.

## 4. Форумда катнашу шартлары

4.1. Форумда аерым башкаручылар һәм коллективлар катнаша ала. Катнашучыларның яше – 12 яшьтән алып 22 яшькә кадәр.

4.2. Форумда катнашу өчен билгеләнгән үрнәктәге гариза бирелә. Һәр иҗади номерга аерым гариза бирелә.

4.3. Бер катнашучы (аерым башкаручы, шулай ук коллектив буларак) һәр номинациядә бер номер тәкъдим итү мөмкинлегенә ия. Бер номинациягә ике һәм аннан да артык номер тәкъдим ителгән булса, Дирекция үзе бары тик бер номерны гына сайларга хокуклы.

4.4. Форумга гариза тутырган очракта, башкаручылар һәм коллективлар аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә рөхсәт бирәләр.

4.5. Форумда катнашучыларны Дирекция сайлап ала.

4.6. Форумның төп этабында катнашыр өчен рәсми чакыру алган башкаручылар һәм коллективлар чакырыла. Катнашучыларның исемлеге гаризаларны кабул итү тәмамланганнан соң, 2 атна эчендә selet.biz сайтында урнаштырыла.

4.7. Катнашучылар Форумга китү пунктына мөстәкыйль рәвештә киләләр. Форумга бару өчен төгәл җыелу вакыты, урыны өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк.

4.8. Форумның һәр катнашучысынның төп этапта үзе белән түбәндәге документлар булырга тиеш:

- РФ паспорт копиясе (2, 3, 5 бит) яки туу турында таныклык;
- 159/У формадагы медицина белешмәсе;
- мәҗбүри медицина иминияте полисы күчермәсе;
- өйдә инфекцияләр юклыгы турында белешмә (Форумга килгәнче 3 көн алдан бирелә).

4.9. Һәр катнашучы чыгыш ясау өчен кирәкле костюмнар һәм җиһазларны кайгыртырга тиеш.

4.10. Форумда катнашу бушлай.

4.11. Форумда катнашучыларга туклану, палаткаларда урнашу, махсус фирмалы раздаткалар тәэмин ителәчәк.

4.12. Катнашучылар әлеге нигезләмәнең барлык шартларын да үтәргә тиеш. Этик нормаларны бозучы катнашучылар Форумның башкарма Дирекциясе карары белән, кайсы этап булуга карамастан, Форумда катнашудан читләштерәләр.

5. Катнашучылар өчен юнәлешләр, бәяләү критерийлары һәм

таләпләр 5.1. **Бию юнәлеше.**

5.1.1. Түбәндәге яшь категорияләрендә уза:

- 1 төркем: 12-14 яшь;

- 2 төркем: 15-18 яшь;

- 3 төркем: 19-22 яшь.

5.1.2 Ике тәҗрибә категорияләрен үз эченә ала:

- А категориясе: «Яңарыш» (тәҗрибәсе 5 елдан кимрәк булган, республикакүләм һәм муниципаль конкусларда югары урын алган башкаручы/коллективлар өчен тәкъдим ителә);

- Б категориясе: «Омтылыш» (тәҗрибәсе 5 елдан күбрәк булган, халыкара, россиякүләм һәм республикакүләм конкурсларда югары урын алган башкаручыларга/коллективларга тәкъдим ителә).

5.1.3. Үз эченә түбәндәге номинацияләрне ала:

- «Халык-сәхнә биюе» (соло, кече форма – 5 кешегә кадәр, ансамбль);

- «Халык-сәхнә биюе стилизациясе» (соло, кече форма – 5 кешегә кадәр, ансамбль);

- «Заманча бию» (соло, кече форма – 5 кешегә кадәр, ансамбль);

- «Эстрада биюе» (соло, кече форма – 5 кешегә кадәр, ансамбль).

5.1.4. Башкаручы яки коллектив 2 чыгыш әзерли: беренчесе – милли татар биюе (ул татар халык, татар биюе стилизациясе һәм заманча татар биюе), икенчесе – теләсә кайсы бер номинациядә чыгыш ясау (п. 5.1.2.).

Номер озынлыгы 4 минуттан артык булырга тиеш түгел. Башкаручы яки коллектив юнәлештә 2 номердан, номинациядә 1 номердан артык күрсәтергә тиеш түгел.

5.1.5. Бәяләү критерийлары:

- башкару техникасы;

- номерларның композицион төзелеше;

- репертуарның башкаручыларның яшь үзенчәлекләренә туры килүе;

- артистизм, эмоциональлек, сәнгать образын ачу;

- репертуарның катлаулылыгы;

- оригинальлек, индивидуальлек;

- музыкальлек һәм номерның сәнгать трактовкасы;

- сценичность (пластика, костюм, реквизит, башкару культурасы).

5.2. **Музыкаль юнәлеш.**

5.2.1. Түбәндәге яшь категорияләрендә уза:

- 1 төркем: 12-15 яшь;

- 2 төркем: 16-19 яшь;

- 3 төркем: 20-22 яшь.

5.2.2. Үз эченә түбәндәге номинацияләрне ала:

- «Эстрада-джаз вокалы» (соло, кече форма – дуэт һәм трио, ансамбль);

- «Татар халык җыры стилизациясе» (соло, кече форма – дуэт һәм трио, ансамбль);

- «Халык вокалы» (соло, кече форма – дуэт һәм трио, ансамбль);

- «Академик вокал» (соло, кече форма – дуэт һәм трио, ансамбль);

- «Автор җыры»;

- «Вокаль-инструменталь ансамбль» (соло, кече форма – дуэт һәм трио, ансамбль).

5.2.3. Башкаручы яки коллектив бары тик бер номинациядә генә катнаша ала.

Номер озынлыгы 4 минуттан артык булырга тиеш түгел. Башкаручы яки коллектив юнәлештә 2 номердан, номинациядә 1 номердан артык күрсәтергә тиеш түгел.

5.2.4. Барлык әсәрләр дә татар телендә башкарыла.

5.2.5. Бәяләү критерийлары:

- музыкальлек, артистизм, музыкаль әсәрнең сәнгать трактовкасы;

- интонация чисталыгы һәм яңгырау сыйфаты;

- тембр матурлылыгы һәм тавыш көче;

- концерт номерның тамашасы;

- сәхнә культурасы;

- репертуар катлаулылыгы һәм аранжировка;

- ансамбль башкаруының техник мөмкинлекләре;

- репертуарның башкаручының мөмкинлекләренә туры килүе;

- башкаручы осталыгы.

5.3. **Театраль юнәлеш**.

5.3.1. Түбәндәге яшь категорияләрендә уза:

- 1 төркем: 12-14 яшь;
- 2 төркем: 15-18 яшь;
- 3 төркем: 19-22 яшь.

5.3.2. Үз эченә түбәндәге номинацияләрне ала:

5.3.2.1. «Нәфис сүз» (соло, иҗади коллектив).

5.3.2.1.1. Катнашучылар ирекле формада 1 әсәр тәкъдим итәләр: чәчмә әсәр, поэзия, әдәби-музыкаль композиция. Номер озынлыгы 5 минуттан артык булырга тиеш түгел. Әдәби-музыкаль композиция өчен 8 минуттан артык түгел.

5.3.2.1.2. Барлык әсәрләр дә татар телендә башкарыла.

5.3.2.1.3. Бәяләү критерийлары:

- әсәр темасын ачуда тулылык һәм тәэсирлелек;

- артистизм, сәнгать образын ачу, башкару дәрәҗәсе;

- дикция;

- башкару осталылыгы;

- оригинальлек, тәэсирлелек, индивидуальлек;

- башкарыла торган әсәрнең катлаулылыгы;

- композицион карар;

- репертуарның башкаручыларның яшь үзенчәлекләренә туры килүе.

5.3.2.2. «Театр драма сәнгате» (соло һәм иҗади коллектив).

5.3.2.2.1. Тәкъдим итү формасы ирекле: моноспектакль, заманча һәм классик авторларның драматик өзекләре, шул исәптән дөнья драматургиясе авторлары, театрның кече формалары – скетч, пародия, оперетта. Һәрбер номерның озынлыгы 15 минуттан артык булырга тиеш түгел. Номинация кысаларында иң яхшы ир-ат, иң яхшы хатын-кыз, 2 план рольләрен башкарганнар билгеләнә.

5.3.2.2.2. Барлык әсәрләр дә татар телендә башкарыла.

5.3.2.2.3. Бәяләү критерийлары:

- әсәр темасын ачуда тулылык һәм тәэсирлелек;

- артистизм, сәнгать образын ачу, башкару дәрәҗәсе;

- дикция;

- башкару осталыгы;

- оригинальлек, тәэсирлелек, индивидуальлек;

- башкарыла торган әсәрнең катлаулылыгы;

- композиционн карар;

- репертуарның башкаручыларның яшь үзенчәлекләренә туры килүе.

5.4. Форумда катнашучыларга түбәндәге техник таләпләр куела:

- фонограмма USB хәтер җайланмасында гына саклана;
- барлык фонограммаларда да башкаручының исем, фамилиясе, коллектив исеме, номинация, яшь төркеме, әсәр исеме күрсәтелергә тиеш (мәсәлән: «Индиго» заманча бию студиясе, заманча бию, 2 төркем: 16-19 яшь, «Филологиня»);

- «плюс»ка, ягъни фонограммага кушылып җырлау тыела;
- бэк-вокал партияләрен керткән, вокалист көен кабатлаучы фонограмма белән куллану тыела.

5.5. Төрле яшьтәге коллективларда яшь категориясе 75%/25% чагыштырмасыннан чыгып билгеләнә.

6. Иҗади лабораторияләр эшчәнлеге, аларда катнашу таләпләре

6.1. Форумның уку-укыту программасы кысаларында һәр юнәлеш өчен («бию юнәлеше», «музыка юнәлеше», «театр юнәлеше») иҗади лабораторияләр эшләячәк.

6.2. Һәр юнәлешнең үз экспертлары бар, шулай итеп, һәр юнәлеш кысаларында берничә лаборатория эшләячәк.

6.3. Иҗади лабораторияләрдә катнашучылар конкурс программасы нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан сайланып алыначак. Катнашучылар арасында индивидуаль башкаручылар, коллективлар һәм коллективлардан сайланып алынган берничә катнашучы була ала (бу экспертлар төркеме карамагында).

6.4. Һәр эксперт үзе сайлап алган төркем белән эшләячәк.

6.5. Һәр лаборатория үзенең иҗади эшен Форумның гала-концертында күрсәтәчәк.

7. Форум дирекциясе

Дирекция Форумны әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы.

Дирекция составы Халыкара «Сәләт» яшьләр белем бирү форумының оештыру комитеты әгъзалары, чакырылган экспертлар арасыннан төзелә һәм «Сәләт» ТРМОФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Форумны әзерләү һәм үткәрү буенча барлык оператив эшне Дирекция башкара:

- Форумның барлык этапларының административ тәэмин итүен башкара;
- Форум программасын әзерли һәм раслый;
- үткәрелү урынын һәм вакытын билгели;
- режиссер төркеменең составын раслый;
- Форум Гала-концерты сценариясе һәм режиссурасын булдыру өчен җавап бирә;
- хәзерге Нигезләмәгә, «Сәләт» ТРМОФ генераль директоры белән килешеп, өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә хокуклы.

Форум Дирекциясенең контактлары:

тел.: +7 9276705671 (эш вакыты: с 9.00-20.00).

email: artsbilerforum@selet.biz.

## 8. Форумның эксперт комиссиясе

Программа чараларын үткәрү өчен эксперт комиссиясе булдырыла.

Форумның эксперт комиссиясе составы Форум идеяләрен популярлаштыруга ярдәм итүче Татарстан Республикасы һәм Рәсәй Федерациясенең атказанган һәм танылган артистлары, актерлары, композиторлары, укытучылары, шагыйрьләре, продюсерлары, режиссерлары һәм башка иҗади элита вәкилләреннән төзелә.

Форумның эксперт комиссиясе Форумда катнашучылар арасыннан лауреатларны билгели.

Барлык катнашучылар да Халыкара «Сәләт» яшьләр белем бирү форумы катнашучысы дипломнары белән бүләкләнә.